**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 ,РТ, Лаишевский район,
село нармонка, ул.Молодежная, д.12а
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН НАРМОНКА АВЫЛЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422610 Лаеш районы,Нармонка авылы
Яшьлэр ур., 12 а анчейорт
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

---

**2022елның «28» ноябре** **162/1 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә Нармонка торак пунктындагы Пановская урамы гражданнары җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Пановка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районының **Нармонка** торак пункты **Пановская урамы** территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән( балачактан көндезге формада белем алучы һәм инвалидларны исәпкә алган студентлардан тыш) 2023 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Нармонка авылы Пановская урамында урам утларын ремонтлау, яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Нармонка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ Солягин А.О.**
**Башлык-Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе: _________________ Солягин А.О.**